# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы парламентының исемен
Татарстан Республикасы законнарында Татарстан
Республикасы Конституциясенә туры китерү
турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең иң югары вәкиллекле, закон чыгару һәм тикшереп тору органының исемен Татарстан Республикасы законнарында Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы законнарында (еллык һәм һәр квартал өчен бюджет турындагы законнардан гайре), Татарстан Республикасы Югары Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка хокукый норматив актларда "Татарстан Республикасы Югары Советы", "Югары Совет" дигән сүзләрне, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең иң югары вәкиллекле, закон чыгару һәм тикшереп тору органы исеме буларак, "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы", "Дәүләт Советы" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

2. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 30 марты
№ 18